«Раслыйм»
МБМБУ «417 нче
балалар бакчасы»
_____________ Р.Ф.Хәйбуллина

**Казан шәһәре Киров районының “Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 417нче катнаш төрдәге балалар бакчасы” мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе**
**2023 – 2024 нче уку елына эш планы**

Кабул ителде:
педагогларның кинәшмәсендә
1 нче беркетмә, 31.08.2023
№ 78 фәрман 01.09.2023

Казан шәһәре Киров районының “Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 417 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы” мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе (1957 елда төзелгән) 1995 елдан бирле эшли. Проект егәрлеге (мощность) – 5 төркем, 95 урын, типлаштырылган торак (яраклаштырылган), мәйданы – 1400,4 кв.м.

Бакча мөдире – Хәйбуллина Рәизия Фидаил кызы.

2022 нчы елның 1 сентябренә фактта булган балалар саны – (23 - 1 яшьтә6айдан алып 3 яшькә кадәрге нәни балалар; һәм - 120 - 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балалар), барлыгы 5 төркем:

1 яшьтәбайдан алып 3 яшькә кадәрге нәниләр төркеме – 1;
3 яшьтән алып 4 яшькә кадәрге 2 нче кечкенәләр төркеме - 1;
4 яшьтән алып 5 яшькә кадәрге урта яшьтәге балалар төркеме - 1;
5 яшьтән алып 6 яшькә кадәрге зурлар (катнаш) төркеме– 1;
6 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге (катнаш логопедия)мәктәпкә хәзерлек төркеме - 1.

Балалар бакчасында 5 төркем 10,5 сәгать дәвамында иртәнге 7.30 сәгатьтән кичке 18.00 сәгатькә кадәр эшли.

Балалар бакчасында түбәндәге бүлмәләр җиһазландырылган:

- музыка һәм спорт залы,
- рус (татар) теле бүлмәсе,
- логопед бүлмәсе,
- медицина бүлмәсе,
- методик бүлмәсе.

Тәрбия һәм белем бирү эшчәнлеге РФ һәм ТР ның Фән һәм Мәгариф Министрлыгы тарафыннан кабул ителгән төп, парциаль, коррекционпрограммаларга таянып башкарыла:

- Основная образовательная программа МБДОУ «Детский сад №417»;
- «Сөенеч», региональная образовательная программа дошкольного образования, Р.К. Шаехова, Издательство «Магариф-вакыт», 2016;
- Программа, учебно-методический комплект «Изучаем русский язык» Гаффарова С. М.;
- УМК «Туган телдә сөйләшәбез» Хазратова Ф. В., Зарипова З.М.;
- С.Н. Николаева «Юный эколог» (программа экологического воспитания в детском саду), Москва: Мозаика-синтез, 2010;
- Л.Д. Глазырина «Физическая культура – дошкольникам», Москва-синтез, 2009;
- Г.Б.Филичева «Развитие речи детей с фонетико-фонематическим недоразвитием речи»;
- Т.Ф.Саулина «Знакомим дошкольников с правилами дорожного движения», «Мозаика-синтез», 2014;
- И.А. Лыкова Программа художественного воспитания, обучения и развития детей 2-7 лет, Москва:Издательский центр «Цветной мир», 2011;
- Р.Б.Стеркина «Основы безопасности детей дошкольного возраста».

**Педагогларның яшь күрсәткечләре:**

| уку елы | барлыгы | 20-25 | 25-30 | 30-49 | 50-54 |
|---|---|---|---|---|---|
| 2022-2023 | 12 | | | 9 – 75% | 3 - 25% |

**Педагогларның хезмәт еллары (стаж) буенча күрсәткечләр:**

| уку елы | педагоглар саны | 1- 3 | 3- 5 | 5-10 | 10-15 | 15-20 | 20- 30 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2022-2023 | 12 | 2 – 16% | | | 1 – 8% | 6-51% | 3-25% |

**Педагогларның белем дәрәҗәләре:**

| уку елы | барлыгы | югары белем б-н | махсус урта белем |
|---|---|---|---|
| 2022-2023 | 10 | 11 -92% | 1- 8% |

Педагогларның белем дәрәҗәләренә анализ ясау шуны күрсәтә: бакчада эшләүче педагогларның якынча 92 % югары белемле.

**Педагогларны аттестацияләү:**

| уку елы | югары категорияле | I (беренче) категорияле | Категория сезләр |
|---|---|---|---|
| 2022-2023 | 6 | 4 | 2 |

Ел дәверендә педагоглар белән һәрдаим көндәлек тәрбия-белем планын язу, балалар һәм әти-әниләр белән ничек эшләргә, нинди әңгәмәләр корырга, төрле эшчәнлекне оештыру буенча, шулай ук балаларның белемнәрен тикшерү буенча методик ярдәм күрсәтелде. Тәрбиячеләр белән һәр төркемдә барлык төр эшчәнлек оештыру дөрес, методик яктан нык һәм җиңел булу ниятеннән перспектив планнар төзелде.

2022-2023 нче уку елында Мухутдинова Р.Р., Пустобаева Л.Х., Шайдуллина Г.Р., Гайнетдинова Р.А., Зинатулина А.А., Самигуллина Э.Р., Камардина Г.Ф., Хамидуллина Ч.Р., Сунгатуллина Р.Г. педагогларның район күләмендә үткәрелгән методик берләшмәдә катнаштылар. Мухутдинова Р.Р., Шайдуллина Г.Р., Гайнетдинова Р.А., Зинатулина А.А., Самигуллина Э.Р., Камардина Г.Ф., Хамидуллина Ч.Р., Сунгатуллина Р.Г. Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү буенча педагогларның белемнәрең күтәрү курсларында катнаштылар.

Зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркемнәредәге балалар район конкурсларда «Современный взгляд на произведения С.Я.Маршака», «Современный взгляд на татарские произведения», «Джалиловские чтения», «Туган тел», «Звездный билет», Международный конкурс-фестиваль дип аталган конкурсларда катнаштылар.

Бакча кыйссаларында планда каралган барлык чаралар да белем күтәрү өчен эшлекле уеннар, түгәрәк өстәлләр, семинар-практикумнар, смотр - конкурслар, барысы да әйбәт кенә уздырылды.

Һәр педагог үз мөмкинлегенә таянып, эш юнәлешләре буенча ел буена әти-әниләр һәм коллектив белән төрле чыгышлар, шәхси әңгәмәләр, «Ачык ишекләр» көне, ачык шөгыльләр, семинар-практикумнар уздырдырылды.

2022-2023 нче уку елына карата кабул ителгән план буенча түбәндәге бурычларны тормышка ашыру буенча тырышып эшләдек:

1. Балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту, аларның физик һәм психик үсеше, иҗади сәләтләрен ачу өчен мөмкинлекләр тудыру, балаларда сәламәт яшәү рәвеше һәм тормыш куркынычсызлыгы нигезләрен күзаллауны формалаштыру;
2.Әхлакый-патриотик тәрбия бирү өлкәсендә заманча методлар һәм эш формалары кулланып, педагогларның һөнәри компетентлыгын үстерү. (Повышение профессионалжной компенентности педагогов в области современных методов и форм по нравственно-патриотическому воспитанию).
3.Мәктәпкәчә белем бирүнең Федераль Дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә тәрбия-белем бирү процессының сыйфатын арттыру максатыннан чыгып педагогларның һөнәри компетентлык эшен дәвам иттерү.

Тәрбиячеләр көндәлек тәрбия-белем бирү планын кулай күрделәр. Алар тәрбия-белем бирү планнарын ел башында кабул ителгән бакчаның еллык планына, шөгыльләр челтәренә, көндәлек тәртипкә, балаларның яшь үзенчәлекләренә һәм мөмкинлекләренә таянып эш иттеләр. Эшләрендә төрле-төрле ысуллар һәм чаралар кулланса лар да, аларның барысы да үсеп килүче шәхеснең төрле яктан үсешен булдыруга юнәлтелгән. Танып белү мәсьәләләре төрле төр эшчәнлек вакытында чишелә: уен, үзара аралашу дәверендә, продуктив эшчәнлектә, махсус оештырылган шөгыльләрдә, физкультура сәламәтләндерү чаралары уздыруда һ.б.

Бакчада 1 кечкенәләр төркеме эшләп килә, анда 23 бала тәрбияләнә. Тәрбиячеләр – Мухутдинова Александрова О.А. нәниләрне беренче көннәреннән үк төрле алымнар һәм чаралар кулланып каршы алалар, аларның яңа социаль шартларга тиз ияләшүләре өчен барлык мөмкинлекләрне дә тудырырга тырыштылар: предметлы үсеш мөхитен кечкенә өй җиһазлары, уенчыклар, уеннар, тулыландырдылар. Бу тәрбиячеләрнең ягымлы сөйләшүләре, барлык балаларга карата мөлаем карашлары, һәр балага шәхси якын килүләре адаптацияләшүнең бик җиңел узуына китерә. “Яңа килгән балаларның бакчага күнегү” беренче кечкенә төркемендә (Самигуллина Э.Р.) фронталь тикшерү уздырылды (фәрман №116 09.12.2022нче ел). Фронталь тикшерүнең максаты: төркемдәге ияләшү чорында балаларга тәрбияви-белем бирү эшен оештыру өчен тудырылган

шартларны өйрәнү Балаларны бакчага ияләштергәндә тәрбиячеләрнең һәр эшне максат куеп, планлаштырып эшләүләренә баланың яңа шартларга тизрәк һәм җиңел ияләшүенә этәргеч ясый.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сәламәтлеге, физик яктан үсеше турында кайгырту – балалар бакчасы эшенең иң әһәмиятле өлеше. Баланың нормаль җитлегүе һәм үсүе өчен, аның организмын ныгыту өчен аерым шартлар тудыру һәм физик тәрбия бирүнең төрле чараларын куллануны таләп итә. Дөрес физик тәрбия бирү эшен бик күп төрле чаралар белән тормышка ашыру өчен һәр төркем тәрбиячеләре көндәлек эшчәнлектә башкаралар. Алар иртәнге гимнастиканы ел дәверендә алып бардылар (җәй-көз  физкультура мәйданчыгында), шөгыльләр вакытында балаларның аруларын булдырмау йөзеннән ял минутлары оештырдылар, эшчәнлекләрнең төрләрен уйлап чиратлаштырдылар.

Физик тәрбия буенча эшне  Хәйбуллина Л.Ә. уңышлы гына алып бара.  Барлык чаралар ярдәмендә ул балаларда физик (җитезлек, осталык, өлгерлек, чыдамлылык), әхлакый (тотнаклылык, оешканлык, мөстәкыйльлек, уңай нәтиҗәләргә ирешүдә үз дигәнедә нык торучанлык, түземлелек) сыйфатлар булдырырга омтыла. Физик тәрбия бирү балаларның хәрәкәтләрен үстерү ярдәмендә тормышка ашырыла. Хәрәкәтләрне үстерү баланың гомуми үсешенә зур йогынты ясаганга күрә, физик күнекмәләрнең нигезе уеннарга кертелә торган табигый хәрәкәтләр күп кулланылды.

**Физик тәрбия күрсәткечләре:**

| | | югары | уртача | уртачадан түбән |
|---|---|---|---|---|
| 2022-2023 | ел башы | 68 | 29 | 3 |
| | ел ахыры | 75 | 25 | 0 |

Бакчада катнаш 1 логопедия төркеме эшләп килә. Балаларның сөйләмдәге кимчелекләрен төзәтү буенча укытучы-логопед Хамидуллина Чулпан Рафисовна, Сунгатуллина Рушания Гусмановна уңышлы гына эшләде. Ул үз эшчәнлеген 3 юнәлештә - тәрбия, үсеш, белем бирү юнәлешендә алып барды.  33 баланың:  19 бала -  мәктәпкә хәзерлек төркемендә, 14 бала өлкәннәр төркемендә.  Ел дәверендә алып барылган нәтиҗәләргә апрель аенда булган ПМПК бәя бирде: мәктәпкә әзерлек төркемендәге 19 бала   (100  %) да яхшы сөйләм белән чыктылар.

Балага акыл тәрбиясе бирү эше дә тәрбиячеләр тарафыннан һәрдаим алып барыла. Бу бурычны алар бакчада уздырыла торган барлык төр эшчәнлек вакытында да тормышка ашыралар. Бигрәк тә уен аша башкаруны кулай күрәбез. Чөнки баланың күзәтүчәнлеге, кызыксынучанлыгы, күз алдына китерү сәләте, үсеш белән бәйләнгән.

| | ел башы (%) | ел ахыры (%) |
|---|---|---|
| Социаль-коммуникатив үсеш | 53,25 | 77,75 |
| Танып белү үсеш | 54,25 | 79,93 |
| Сөйлем  үсеш | 54,25 | 81,15 |
| Нәфис-нәфасәти үсеше | 47,65 | 76,08 |
| Физик үсеш | 48,7 | 72,58 |

Балаларны мәктәпкә  әзерләү, уку эшчәнлеге белән кызыксыну һәм мәктәптә укыйсы килү теләге уяту эше ел дәверендә алып барылды.

Уку елы дәверендә бакча 152 нче номерлы мәктәп белән тыгыз элемтәдә эшләде. Бергә оештырылган җыелышлар, үзара дәресләрдә булу, чыгышлар ике як педагоглары өчен дә бик файдалы булды.

Еллык план нигезендә бакчаның мәктәпкә әзерлек  төркемендә фронталь тикшерү “Балаларның мәктәптә белем алырга әзерлеге”  уздырылды. Бу тикшерү дәверендә төркемдә уздырыла торган тәрбия, белем, уен педагогларның эти - әниләр белән башкарылган эшчәнлегенә бәя бирелде, төрле төр эшчәнлек оештыру өчен тудырылган шартлар (санитария-гигиена, көндәлек эшчәнлекнең үтәлеше, балаларның тормыш иминлеген һәм сәламәтлеген саклау буенча таләпләр, янгын куркынычсызлыгы буенча торыш һ.б.ш.).

Бу төркемдә   – Самигуллина Э.Р., Камардина ГФ.  эшлиләр, төркемдәге балалар  саны – 32 . Педагоглар бер-берсе белән дус, яхшы мөнәсәбәттә булу, аңлашып һәм ярдәмләшеп эшләү нәтиҗәсендә эти-әниләр тарафыннан мәхәббәт һәм ышаныч яуладылар. Шушындый яхшы мөнәсәбәт яулау нигезендә төркемдәге барлык эшчәнлек тә балаларга тәрбия һәм белем бирү өстендә иңгә-иң

тотынышып эшчәнлек оештыруга китерде. Тикшерү вакытында балаларның белем күнекмәләрен тикшерү нәтиҗәләре түбәндәгечә:

| | югары | уртача |
|---|---|---|
| Социаль-коммуникатив үсеш | 80% | 20% |
| Танып белү үсеш | 80% | 20% |
| Сөйлем үсеш | 76% | 34% |
| Нәфис-нәфасәти үсеше | 90% | 10% |
| Физик үсеш | 85% | 15% |

Педагоглар көндәлек тәрбия-белем бирүне календарь план буенча алып баралар. Барлык документлар эстетик яктан матур, чиста һәм пөхтә итеп алып барыла. Иҗади лабораторияләрендә эти-әниләр өчен төрле юнәлештәге чыгышлар, педагогик утырышларда катнашкан материаллар җыйналган.

Балаларның сәламәтлеге нык булу өчен яхшы, чиста шартлар тудыру зарур. Бу эшне төркемдә кече тәрбияче – Зайнутдинова Г.М. башкара. Төркемдәге чисталык барлык санитария-гигиена һәм САНПИН таләпләренә туры килә. Кече тәрбияче һәрдаим балаларның сәламәтлеген саклау ниятеннән көндәлек һәм атналык чистарту-җыештыру планын вакытында үтәп килгәнгә күрә ел дәверендә шәфкать туташы һәм табиб тарафыннан ризасызлыклар белдерү булмады.

Төркемдә балалар белән һәрдаим шәфкатьлелек һәм үзара уңай мөнәсәбәтләр тәрбияләү өстендә әңгәмәләр, сөйләшүләр, төрле мисаллар китереп, матур әдәбият һәм балалар фольклоры файдаланып башкарыла.

Тәрбия-белем бирү эше уңышлы һәм нәтиҗәле булсын өчен гаилә һәм балалар бакчасының алып барган тәрбияви чаралары да бер-берсенә теләктәшле булырга тиеш, бер үк максатка омтылган булуы кирәк. Бакчаның, гаиләнең бердәм эш итүе баланың һәркайда, һәрбер урында бер үк төрле, бер-берсенә каршы булмаган теләкләр кую зарурлыгын күрсәтә.

Безнең бакчада эти-әниләр белән эшләүнең төрле формаларын, оештыру чараларын файдаланып тормышка ашырдык. Әти-әниләр белән берлектә оештырылган гомуми җыелышлар, консультацияләр («Өйдә бала белән ничек шөгылллләнергә», « Мәктәпкәчә яшьтәге бала шәхесен үстерүдә уенның роле», « Мәктәпкәчә кече яшьтәге балаларда мөстәкыйльлек һәм үз-үзеңә хезмәт күрсәтү тәрбияләү »), очрашулар, бәйрәмнәр (“Кәз бәйрәме”, “Яңа ел бәйрәме”, “Әни бәйрәме”), ачык ишекләр (“Балалар белән УМК “Туган телдә сөйләшәбез” кулланылган оштырылган белем бирү карау”), бәйгеләр безнең барыбызга да файдалы узды.

Бакча татар телендәге тәрбия-белем бирү учагы буларак, эшебезнең төп юнәлеше - туган төбәкне өйрәнеп, халкыбызның гасырлар буена тупланып килгән мирасын, күңел бизәкләренең матурлыкларын балаларга җиткерү, сабыйларда милли мәдәнияткә мәхәббәт тәрбияләү, ана теленә карата мәхәббәт тәрбияләү. Музыка җитәкчесе Зинатулина А.А. һәм тәрбиячеләр милли бәйрәмнәребез турында белем бирүне максат итеп алып «Нәүрүз», «Карга боткасы», «Сабантуй», бәйрәмнәре үткәрде.

Безнең балалар бакчасы “Туган телдә сөйләшәбез” укыту-методик кулланмасы белән эшли. Эшебездә түбәндәге бурычларны күз алдында тоттык:

- Балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү;
- Бәйләнешле сөйләм үстерү;
- Тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау (тоемлау) сәләте булдыру.

2022-2023 ел планы буенча балаларның төрле яктан үсешенә йогынты ясаучы шөгыйльләрнең белем бирү эшчәнлегендә УМК проекты кулланып үткәрелгән чараларны күмәк тикшерүләр узды (“Шигырь бәйгесе уздыру (татар һәм рус телендә шигырьләрне сәнгатьле итеп яттан сөйләү)”, “Тукай безнең йөрәкләрдә”).

**2023– 2024 нче уку елына алда торган бурычлар:**

1. Балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту, аларның физик һәм психик яктан үсешег, иҗади сәләтләрен ачу өчен мөмкинлекләр тудыру, балаларда сәламәт яшәү рәвеше һәм тормыш куркынычсызлыгы нигезләрен күзаллауны формалаштыру;

2. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда туган якка, туган телгә карата мәхәббәт тәрбияләүне дәвам итү. Бу юнәлештәге эшне УМК "Туган телдә сөйләшәбез" материаллары аша тормышка ашыру, татар телендә актив аралашуга ирешү,

3.Яңа Федераль белем бирү программасын гамәлгә кертү шартларында, белем бирү процессының сыйфатын күтәрү максатында, педагогларның һөнәри компетентлык арттыру.

| № | эчтәлек | уздыру вакыты | җаваплылар |
|---|---|---|---|
| ***<u>I. ЭШЧӘНЛЕКНЕ ОЕШТЫРУ БЕЛӘН ИДАРӘ ИТҮ</u>*** | | | |
| 1.1. | Педагогларны бакчаның инструктив хокуки документлары белән таныштыру | ел дәвамында | мөдир Хәйбуллина Р.Ф. |
| **Педагогларның квалификацияләрен күтәрү** | | | |
| 1.1. | Педагогларның методик берләшмәләрдә катнашулары | ел дәвамында | мөдир Хәйбуллина Р.Ф., өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р. |
| 1.2. | Мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү турындагы методик әсбаплар белән таныштыру | ел дәвамында | мөдир Хәйбуллина Р.Ф., өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р. |
| 1.3. | Укыту бүлегендә педагогларның басмалар җыентыгы | ел дәвамында | өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р. |
| 1.4. | Педагогларны мастер-класс һәм төрле семинарларга җибәрү | ел дәвамында | мөдир Хәйбуллина Р.Ф., өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р. |
| **Аттестация** | | | |
| 1.1. | Самигуллина Э.Р. - тәрбияче<br>Гайнетдинова Р.А. - тәрбияче<br>Зинатулина А.А. – музыка җитәкчесе<br>югары квалификацион катигориягә аттестация уздыру; | октябрь-декабрь 2021 | мөдир Хәйбуллина Р.Ф., өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р. |
| | Инструктажлар уздыру<br>• сакчыл эш итү һәм техник куркынычсызлык турында;<br>• янгын куркынычсызлыгы турында;<br>• балаларның тормыш иминлеген һәм сәламәтлеген саклау буенча. | елга 2 тапкыр<br>елга 2 тапкыр<br>3 айга бер | мөдир Хәйбуллина Р.Ф.<br>Салаватуллина З.Ю. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.2. | Күргәзмәләр оштыру<br>• «Без Казанда яшибез» рәсем күргәзмәсе<br>• Ата – аналар белән берлектә «Көзге уңышлар» кул эшләнмәләреннән күргәзмә<br>• «Кышкы бизәкләр»<br>• «Безнең әниләр»<br>• «Габдулла Тукай әсәрләре буенча» рәсемнәр күргәзмәсе<br>• Рәсем күргәзмәсе «Мин тынычлык ясыйм»<br>Смотр-конкурслар<br>• «Яңа уку елына әзерлек»<br>• Бәйрәмгә төркемне бизибез (ата-аналар белән конкурс)<br>• «Балалар бакчасы территориясендәге иң яхшы участок» | IX-2023<br>X -2023<br>XII - 2023<br>II - 2024<br>VI - 2024<br>V- 2024<br>IX-2023<br>XII-2023<br>V-VII - 2023 | Хайбуллина Л.А.<br>Пустобаева Л.Х.<br>Самигуллина Э.Р.<br>Гайнетдинова Р.А.<br>Мухутдинова Р.Р.<br>Ялышева Г.Г.<br>өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р., тәрбиячеләр<br>тәрбиячеләр<br>тәрбиячеләр |
| 1.3. | Район, шәһәр, Республика күләмендә уздырыла торган чараларда һәм халыкара смотр-конкурсларда катнашу.<br>• Йолдызлы билет;<br>• Йолдыз бул - музыкаль конкурс;<br>• Г.Тукай әсәрләрен яттан сөйләү «Туган тел» конкурсы;<br>• «Сәламәтләндерү буенча иң яхшы территория». | ел дәвамендә<br>II -2024<br>III -2024<br>IV -2024<br>VI -2024 | мөдир Хәйбуллина Р.Ф., өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р., тәрбиячеләр<br>тәрбиячеләр, укытучы-логопедлар Хамидуллина Ч.Р., Сунгатуллина Р.Г.<br>музыка җитәкчесе Зинатулина А.А., тәрбиячеләр<br>тәрбиячеләр Пустобаева Л.Х., Гайнетдинова Р.А.<br>мөдир Хәйбуллина Р.Ф., өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р., тәрбиячеләр |
| ***<u>II. ТӘРБИЯЧЕЛӘРНЕҢ ЭШЕН ӨЙРӘНҮ ҺӘМ КОНТРОЛЬ</u>*** | | | |
| 2.1. | Яңа 2023-2024 уку елына әзерлек | фронталь тикшерү | IX – 2023<br>мөдир Хәйбуллина Р.Ф., өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р. тәрбиячеләр Самигуллина Э.Р. Пустобаева Л.Х. Зинатулина А.А. Сунгатуллина Р.Г. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2.2. | «Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга экологик тәрбия бирү эшен оештыру»<br>«Организация работы по экологическому воспитанию детей дошкольного возраста» | тематик тикшерү | X - 2023 | мөдир Хәйбуллина Р.Ф., өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р. Пустобаева Л.Х. Гайнетдинова Р.А. |
| 2.3. | Яңа килгән балаларның бакчага ияләшү | фронталь тикшерү | XII – 2023 | мөдир Хәйбуллина Р.Ф., өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р. |
| 2.4. | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә «Туган телдә сөйләшәбез» УМКны гамәлгә ашыру кысаларында мәктәпкәчә яшьтәге балаларны татар теленә өйрәтү эшен үстерүдә . предметлы-үстерешле мохитен оештыру.<br>Организация развивающей предметно-пространственной среды по обучению дошкольников татарскому языку в рамках реализации УМК «Туган телдә сөйләшәбез» в ДОУ. | Тематик тикшерү | II-2024 | мөдир Хәйбуллина Р.Ф., өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р. Пустобаева Л.Х. Самигуллина Э.Р. |
| 2.5. | Балаларның мәктәптә белем алырга әзерлеге (мәктәпкә әзерлек төркеме) | фронталь тикшерү | V-2024 | мөдир Хәйбуллина Р.Ф., өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р. |
| ***III.ПЕДАГОГИК КИҢӘШМӘЛӘР*** | | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3.1. | Тема: Яңа уку елына әзерлек. 2023-2024нче уку елына балалар бакчасының төп үсеш юнәлешләре.<br>3.1.1. Педагогик киңәшмәнең сәркатибен сайлау;<br>3.1.2. 2023-2024нче уку елына еллык планны, дәрес челтәрләрен, көндәлек режимны (елның салкын чоры), тәрбия һәм белем бирү эшчәнлеген планлаштыру формаларын, белгечләрнең, тәрбиячеләрнең эш планнарын, комплекслы тематик планлаштыруны раслау; яңа уку елына эш планын кабул итү;<br>3.1.3. Яңа уку елында, 01.10.2023нче елдан, өстәмә белем бирү буенча эш планнарын раслау;<br>3.1.4. Аттестация узар очен кирәкле яңа норматив документлар.<br>3.1.5. Август ае конференциясе нәтиҗәләре белән таныштыру.<br>3.1.6. Федераль белем бирү программасын гамәлгә ашыру үзенчәлекләре.<br>Тема: Основные направления развития детского сада на 2023-2024 учебный год.<br>3.1.1.Выбор секретаря педагогического совета.<br>3.1.2.Утверждение основных направлений развития детского сада на 2023-2024 учебный год, годового плана на 2023-2024 учебный год, сетки занятий, режима дня (холодный период года); формы планирования воспитательно-образовательной работы, планов работы специалистов, воспитателей; комплексно-тематического планирования.<br>3.1.3.Организация дополнительных образовательных услуг в новом учебном году с 01.10.2023г. Утверждение планов работы по дополнительному образованию.<br>3.1.4.Новые нормативные документы по аттестации.<br>3.1.5.Итоги августовской конференции.<br>3.1.6. Особенности реализации ФОП. | VIII– 2023 | мөдир<br>Хәйбуллина Р.Ф.<br>өлкән тәрбияче<br>Шайдуллина Г.Р. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3.2. | Тема: Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда экологик культура нигезләрен формалаштыру.<br>Максат: мәктәпкәчә яшьтәге балаларда экологик культура нигезләрен формалаштыру буенча балалар бакчасында эшне камилләштерү, педагогларның һөнәри дәрәҗәсен күтәрү.<br>3.2.1. Алдагы педагогик совет карарын үтәү нәтиҗәләре турында.<br>3.2.2. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда табигатьне күзәтү барышында әйләнә-тирә дөньга карата кызыксыну һәм сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү.<br>3.2.3. Өлкән мәктәпкәчә яшьтәге балаларның әйләнә-тирә дөньяга карата танып белү активлыгын һәм танып белү активлыгын һәм сакчыл мөнәсәбәтен үстерү чарасы буларак проект һәм тикшеренү эшчәнлеген оештыру.<br>3.2.4. Балалар эксперимент үзәкләре, аларны оештыру һәм куллану.<br>3.2.5. «Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга экологик тәрбия бирү эшен оештыру» тематик контроль нәтиҗәләре.<br>Тема Формирование основ экологической культуры дошкольников<br>Цель: совершенствование работы в детском саду по формированию у дошкольников основ экологической культуры, повышение профессионального уровня педагогов.<br>3.2.1. Об итогах выполнения решения предыдущего педагогического совета.<br>3.2.2. Воспитание у дошкольников любознательности и бережного отношения к окружающему миру в процессе наблюдений за природой.<br>3.2.3. Организация проектной и исследовательской деятельности как средство развития познавательной активности и бережного отношения к окружающему миру детей старшего дошкольного возраста.<br>3.2.4. Центры детского экспериментирования, их организация и использование.<br>3.2.5. Итоги тематического контроля «Организация работы по экологическому воспитанию детей дошкольного возраста». | XI - 2023 | өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р.<br><br>Пустобаева Л.Х.<br><br>Камардина Г.Ф.<br><br>Гайнетдинова Р.А. |
| 3.3. | Тема: Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны Татарстан Республикасының ике дәүләт теленә өйрәтү өчен балаларның барлык эшчәнлек төрләрендә заманча алымнар кулланып шартлар тудыру.<br>Максат: Татарстан Республикасында мәктәпкәчә яшьтәге балаларны дәүләт телләренә өйрәтү эшен системага салу.<br>3.3.1. Алдагы педагогик совет карарының үтәлешен анализлау.<br>3.3.2. «Туган телдә сөләйәшебез «УМКны тормышка ашыру кысаларында мәктәпкәчә яшьтәге балаларны татар теленә өйрәтү буенча предметлы- | II - 2024 | мөдир Хәйбуллина Р.Ф.<br>өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | үстерешле мохитен оештыру» тематик контроль нәтиҗәләре.<br>3.3.3. Балалар эшчәнлегенең төрле формаларында һәм төрләрендә мәктәпкәчә яшьтәге балаларны Татарстан республикасының ике дәүләт теленә өйрәткәндә белем бирү процессында катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге;<br>3.3.4. «Тәрбиячеләрнең УМК «Туган телдә сөйләшәбез» буенча төркемнәрдәге эшенең эчтәлеге (уен эшчәнлеген оештыру).<br>Тема: «Современные подходы к созданию условий для обучения дошкольников двум государственным языкам Республики Татарстан во всех видах детской деятельности»<br>Цель: Систематизация работы по обучению дошкольников государственным языкам РТ.<br>3.3.1. Анализ выполнения решения предыдущего педагогического совета.<br>3.3.2. Итоги тематического контроля «Организация развивающей предметно-пространственной среды по обучению дошкольников татарскому языку в рамках реализации УМК «Туган телдә сөйләшәбез в ДОУ».<br>3.3.3. «Взаимодействие всех участников образовательного процесса в различных формах и видах детской деятельности при обучении дошкольников двум государственным языкам РТ».<br>3.3.4. «Содержание работы воспитателей в группах по УМК «Туган телдә сөйләшәбез» (организация игровой деятельности). | | тәрбияче<br>Мухутдинова Р.Р.<br><br>тәрбияче<br>Самигуллина Э.Р. |
| 3.4. | Тема: 2023 – 2024 уку елы йомгаклары<br>3.4.1 Еллык укыту – тәрбия эшенә анализ ясау;<br>3.4.2.«Безнең унышлар» – төркемдәге тәрбиячеләрнең, хезмәткәрләрнең ел буе эшләгән эшләре турында отчет;<br>3.4.3. 2024 – 2025-нче уку елына план – проект турында киңәшү;<br>3.4.4. «Балаларның мәктәптә белем алырга әзерлеге» фронталь тикшерүләрне анализлау;<br>3.4.5. Чыгарылыш төркем балаларының мәктәпкә әзерлеге турындагы мәгълүматлар;<br>3.4.6. Җәйге сәламәтләндерү планын кабул итү. | V - 2024 | мөдир<br>Хәйбуллина Р.Ф.<br>тәрбиячеләр<br><br>өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р.<br>өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р.<br>тәрбияче Пустобаева Л.Х.<br><br>Зиганшина Л.В. |
| ***IV. СЕМИНАР - ПРАКТИКУМНАР*** | | | |
| 4.1. | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе педагогларнын игълан ителгән категориягә аттестацияләү.<br>Максат: аттестация узучы педагогларга методик һәм психологик ярдәм күрсәтү.<br>Максат: педагогларга методик һәм аттестация узучыларга психологик ярдәм күрсәтү.<br>Аттестация педагогов ДОУ на заявленную категорию.<br>Цель: оказание методической и психологической | IX- 2023 | өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | помощи аттестующимся педагогам. | | |
| 4.2. | Мәктәпкәче белем бирү учреждениесендә сәламәтләндерү өлкәсендә инновацион технологияләр.<br>Инновационные технологии в оздоровительной работе в ДОУ. | X- 2023 | физик тәрбия укытучысы Сафина Л.И. |
| 4.3. | Балаларга татар телен өйрәтүдә мәгълүмати-коммуникатив технологияләр куллану.<br>Использование ИКТ при обучении детей татарскому языку. | XI- 2023 | Шайдуллина Г.Р. |
| 4.4. | Балаларның сөйләм телен үстерәбез: балалар сөйләменең төп юнәлешләре (яшь төркемнәре буенча; сүз байлыгын үстерү.<br>Развиваем речь детей: главные направления речи детей (по возрастным группам; развитие словаря. | I- 2024 | укытучы-логопед Хамидуллина Ч.Р. |
| 4.5. | Әхлакый-патриотик тәрбия бирү буенча балалар белән эшләүнең заманча ысуллары һәм формалары.<br>Современные методы и формы работы с детьми по нравственно-патриотическому воспитанию. | III- 2024 | тәрбияче Ялышева Г.Г. |
| 4.6. | Балаларга экологик тәрбия бирү чарасы буларак уеннар.<br>Игры как средство экологического воспитания детей. | IV - 2024 | тәрбияче Пустобаева Л.Х. |
| ***<u>V. КОЛЛЕКТИВ ТИКШЕРҮЛӘР</u>*** | | | |
| 5.1. | Бергәләп педагогларның шөгыльләрен карау. | Ел дәвамында | мөдир Хәйбуллина Р.Ф. өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р. тәрбиячеләр |
| 5.2. | Спорт залында, урамда булганда мәктәпкәчә яшьтәге балаларның хәрәкәт активлыгын оештыру.<br>Организация двигательной активности детей дошкольного возраста в спортивном зале, на прогулке. | XI - 2023 | мөдир Хәйбуллина Р.Ф. өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р. тәрбиячеләр |
| 5.3. | Өстәмә белем бирү буенча шөгыльләр карау.<br><br>Просмотры занятий по дополнительному образованию | III - 2024 | Өстәмә белем бирү җитәкчеләре |
| 5.4. | Шигырь бәйгесе уздыру (татар һәм рус телендә шигырьләрне сәнгатьле итеп яттан сөйләү) | IV - 2024 | Тәрбиячеләр |
| ***<u>VI. КОНСУЛЬТАЦИЯЛӘР</u>*** | | | |
| 6.1. | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның организмына иртәнге зарядканың йогынтысы.<br>Влияние утренней зарядки на организм ребенка дошкольного возраста» | IX-2023 | физик тәрбия укытучысы Сафина Л.И. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| 6.2. | Баланың тормышында музыкаль-ритмик уеннар.<br>Музыкально-ритмические игры в жизни ребенка. | XI-2023 | музыка җитекчесе Зинатулина А.А. |
| 6.3. | Төркем тәрбиячеләренең татар телендә үткән материалны кабатлау һәм ныгыту өчен УМК «Туган телдә сөйләшәбез»гә нигезләнеп дидактик, сюжетлы-рольле уеннар куллану | I-2024 | тәрбияче Шайдуллина Г.Р. |
| 6.4. | Логопед төркеменә йөрүче мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләмендәге бозуларга характиристика.<br>Характеристика нарушений речи у дошкольников, посещающих логопедические группы | III - 2024 | укутучы-логопед Сунгатуллина Р.Г. |

***<u>VII. МЕТОДИК БҮЛМӘНЕ ТУЛЫЛАНДЫРУ</u>***

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7.1. | Тәрбиячеләр өчен информацион стенд яңарту | IX- 2023 | өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р. |
| 7.2. | Тәрбиячеләрнең үз белемнәрен күтәрү буенча планнарын төзү | X-2023 | Педагоглар |
| 7.3. | УМК “Туган телдә сөйләшәбез” буенча күрсәтмә һәм методик материалларны тулыландыру | ел дәвамында | өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р., тәрбиячеләр |
| 7.4. | Ике дәүләт телендәге балалар әдәбияты китапларын туплау | Ел дәвамында | Мөдир,<br>тәрбиячеләр |
| 7.5. | Шөгыльләрдә куллану өчен дидактик уенчыклар, кулланмалар булдыру | ел дәвамында | Тәрбиячеләр |
| 7.6 | Аттестация почмагын әзерләү, җиһазлау | IX-X 2023 | өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р. |
| 7.7 | Методик бүлмәдә балаларны ике дәүләт теленә өйрәтү буенча тәрбиячеләрнең эш тәҗрибәсеннән чыгып төзелгән эшкәртмәләрен туплау | Ел дәвамында | өлкән тәрбияче,<br>тәрбиячеләр |
| 7.8. | Педагогларның портфолиоларын эш күрсәткечләре буенча тулыландырып тору | Ел дәвамында | өлкән тәрбияче,<br>педагоглар |

***<u>VIII. ӘТИ - ӘНИЛӘР БЕЛӘН ЭШ</u>***

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8.1. | Яңа уку елының бурычлары һәм максатлары (гомуми әти-әниләр җыелышы) | IX- 2023 | Мөдир Хәйбуллина Р.Ф.<br>өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р.<br>тәрбиячеләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8.2. | Ачык ишекләр көне:<br>• Балалар белән шөгыльләр карау | X- 2023<br>IV-2024 | Мөдир Хәйбуллина Р.Ф., өлкән тәрбияче Шайдуллина Г.Р., тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе Зинатулина, физик тәрбия укытучысы Сафина Л.И., укытучы-логопед Хамидуллина Ч.Р., Сунгатуллина Р.Г. |
| 8.3. | Консультацияләр:<br>- Гаиләдә ялны оештыру – булачак китап укучыны тәрбияләү. (Организация досуга в семье – воспитание будущего читателя).<br>-Балалар белән бергә уйнагыз.<br>-Балаларның дөрес сөйләмен формалаштыруда гаилә белән мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең үзара хезмәттәшлеге. (Взаимодействие ДОУ и семьи в формировании правильной речи ребенка).<br>-Мәктәпкәчә яшьтәге баланың шәхесен үстерүдә уеннарның әһәмияте. (Роль игры в развитии личности ребенка дошкольного возраста).<br>-Бала мәктәп бусагасында. 7 яшьлек балаларның үсеш үзенчәлекләре. (Ребенок на пороге школы. Особенности развития детей 7 лет) | XI- 2023<br>XII- 2023<br>I -2024<br>III -2024<br>VI - 2024 | тәрбиячеләр<br>тәрбиячеләр<br>укытучы-логопед Хамидуллина Ч.Р., Сунгатуллина Р.Г.<br>тәрбиячеләр<br>тәрбияче Пустобаева Л.Х. |
| 8.4. | Төркемнәрдә әти-әниләр җыелышлары | кв-га 1 тап. | тәрбиячеләр |
| 8.5. | Әти - әниләр өчен мәгълүматлар:<br>-Яңа килгән балаларның бакчага күнегүләре.<br>-Сәламәтлекне ныгыту чарасы буларак өйдә һәм балалар бакчасында көндәлек режимны оештыру.<br>-Без татар телен өйрәнәбез.<br>-Бала һәм юл кагыйдәләре. | IX – 2023<br>XII – 2023 | тәрбиячеләр<br>тәрбиячеләр<br>тәрбиячеләр<br>тәрбиячеләр |
| 8.6. | *ЧЫГЫШЛАР:*<br>-Балалар бакчасы шартларында яңа килгән нәниләрнең адаптациясе.<br>-Сәламәт белем бирә торган мохит – сәламәт бала.<br>-Баланың дөрес сөйләмен формалаштыруда мәктәпкәчә белем белән гаиләнең үзара хезмәттәшлеге. (Взаимодействие ДОУ и семьи в формировании правильной речи ребенка)<br>-Җәйге чорда балаларның имгәнүләрен профилактикалау. (Профилактика детского травматизма в летний период). | IX - 2023<br>XI – 2023<br>IV - 2024 | тәрбияче Камардина Г.Ф.<br>укытучы-логопед Хамидуллина Ч.Р.<br>тәрбиячеләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | -Булачак беренче сыйныф укучысы (ата-аналарга киңәшләр). (Будущий первоклассник (советы родителям). | V - 2024 | тәрбияче Пустобаева Л.Х. |
| ***<u>IX. АДМИНИСТРАТИВ-ХУҖАЛЫК ЭШЛӘРЕ</u>*** | | | |
| 9.1. | *ТЕРРИТОРИЯДӘГЕ ЭШЛӘР*<br>- куакларны тигезләү;<br>- корыган агачларны һәм куакларларны кисү;<br>- чәчәкләр, куаклар утырту;<br>-уен һәм спорт мәйданчыгында буяу эшләре | IX – X - 2023<br><br>V-2024 | хуҗалык эшеләре мөдире Салаватуллина З.Ю. |
| 9.2. | - җылылык системасына опрессовка<br>- түбәдән кар, боз сөңгеләре төшерү | V – VI - 2023<br>I – IV – 2024 | хуҗалык эше мөдире Салаватуллина З.Ю. |
| ***<u>X.УТЫРЫШЛАР</u>*** | | | |
| 10.1. | Балалар бакчасының эшчәнлегендә 2023–2024 уку елына төп юнәлешләр<br>Хезмәткәрләрнең эш графиклары<br>Балаларның тормыш куркынычсызлыгы турында инструктаж<br>Җәйге сәламәтләндерү һәм чыныктыру эшләренә нәтиҗәләр | IX - 2023 | мөдир Хәйбуллина Р.Ф. |
| 10.2. | Беренче яртыеллыкка нәтиҗәләр: сәламәтләндерү эшләренең нәтиҗәләре;<br>2024 елга отпуск графигын кабул итү | XII – 2023 | мөдир Хәйбуллина Р.Ф., профком рәисе Пустобаева Л.И. |
| 10.3. | Җәйге сәламәтләндерү һәм чыныктыру эшләренә план кабул итү;<br>Җәйге чорда витаминлаштырылган ризыклар белән тәэмин итү;<br>Балаларның тормыш куркынычсызлыгы турында инструктаж. | V - 2024 | мөдир Хәйбуллина Р.Ф., кладовщик Салаватуллина З.Ю.<br>шәфкать туташы Зиганшина Л.В. |